МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08. 08. 2014 г. Казань № 289

**2013 нче елның 26 нчы августынна кабул ителән 277 нче номерлы Татарстан Республикасы икътисад Министрлыгының кара һәм төсле металларның ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сатуны лицензияләштерү буенча дәүләт хезмәте турында Администатив регламентка үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнар белән яраштырырлык өчен **боерам**:

1. 2013 нче елның 26 нчы августынна кабул ителән 277 нче номерлы Татарстан Республикасы икътисад Министрлыгының кара һәм төсле металларның ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сатуны лицензияләштерү буенча дәүләт хезмәте турында Администатив регламентка киләсе үзгәрешләр кертергә:

2 булегенә:

«Стандарт эчтәлегенең таләбе» графасының 2.10 пунктында «ОКАТО 92401000000» сүзләрен «ОКТМО 92701000» сүзләре белән алмаштырырга;

2.12 нче пунктның «Стандарт эчтәлегенең таләбе» дип аталган бүлекнең беренче абзацын киләсе редакциядә бастырырга:

«Шундый дәүләт хезмәтне алыр һәм көтү өчен максималҗ срогын 15 минут дип кабул итәргә.»;

«Стандарт эчтәлегенең таләбе» графасының 2.15 нче пунктына киләсе 4-6 нчы пунктлар өстәргә:

«4) документлар кабул итү, бирү пунклары иҗтимагый транспорт йөри торган җирдә урнашырга тиеш;

5) гариза бирүчеләрне кабул итү өчен кирәкле күләмдә специалистлар һәм бүлмүлүр белүн тәмин итү;

6) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт бирү порталында, «Интернет» челтәренең информацион ресурсарында, информацион стендларда дәүләт хезләтенең ысулы, тәртибе һәм вакыты турында тулы информация булу.»;

бишенче абзацны чыгарырга;

яңа киләсе 2.16 нчы пункт белән тулыландырырга :

| | | |
|---|---|---|
| 2.16 Күптөрле дәүләт һәм муниципаль хезмәт бирү центрларында дәүләт хезмәте бирү үзенчәлекләре | Күптөрле дәүләт һәм муниципаль хезмәт бирү центрларында дәүләт хезмәте бирүне (түбәндәрәк – МФЦ) концультацияне, кабул итүне һәм документларны бирүне МФЦ специалистлары башкара. | |

2.16 нчы пунктны 2.17 нче пункт дип санарга;

3 бүлектә:

бүлекнең исемен киләсе редакциядә бастырырга:

«Күптөрле дәүләт һәм муниципаль хезмәт бирү центрларында дәүләт хезмәте бирү үзенчәлекләре, состав, административ процедураларың состав, эзлеклелек һәм эшләү вакыты, аларны эшләү тәртибе таләпләре, шул хакта электрон формада»;

яңа киләсе эчтәлектәге 3.3.4 – 3.3.5 пунктлар белән тулыландыру:

«3.3.4. Бүлекнең белгече электрон формада ведомство арасындагы электрон үзара тәэсир итү системасы аркылы сорау җибәрде:

Татарстан Республикасы Федераль идарәлеге казначейлыгына лицензия бирү өчен дәүләт җыемын түләү хакында раслаучы мәгълүмат җибәрү;

Татарстан Республикасы Федераль салым түләү эшләре идарәлегенә Бердәм дәүләт реесторының юридик шәхесләре яки Бердәм дәүләт реесторының индивидуаль эшмәкәрләре турында мәгълүмат җибәрү;

Татарстан Республикасы буенча кадастра һәм картография буенча, шәхси милеккә хокуклы булуы, яки башка законлык нигезендә җир участогы, бина, төзелешләрнең Федераль эшләр буенча дәүләт теркәү идарәлегенә алырга теләүченең лицензиясе булуы турында мәгълүмат җибәрү.

Тиешле пункт белән билгеләнгән планнан тыш тикшерүләр хакындагы процедуралар приказ чыккан вакытның бер көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү сораулары.

3.3.5. Тәэмин итеп тору белгечләре ведомство арасындагы электрон үзара тәэсир итү системасы аркылы кирәкле документларны (мәгълүматны) соратып алалар.

Әгәр әзерләнү вакыты дәверендә ведомство арасындагы сорауларга җибәрелгән җаваплар Татарстан Республикасы федераль законнары, Россия Федерациясе Хакимияте законнарына туры килгән хокуки актлары урнашылмаган булса, тиешле пункт белән билгеләнгән процедуралар ведомство арасындагы сорауларның оешмага җибәрелгән документларның һәм мәгълүматның бирү биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кире кагу турында Министрлыкка җибәрегән документлар (мәгълүматлар) яки белдерүләр.»;

3.3.4 – 3.3.15 бүлекләре 3.3.6 – 3.3.17 бүлекләренә туры килә;

3.3.4 абзацындагы «алдагы процедураның азагы» сүзләрен «планнан тыш тикшерүләр турында приказ чыгару» сүзләренә алыштырырга;

икенче абзацның 3.3.8 пунктындагы «3.3.4» саннарын «3.3.6» саннарына алыштырырга;

беренче абзацның 3.3.11 пунктындагы «3.3. 5 – 3.3.7» саннарын «3.3.7 – 3.3.9» саннарына алыштырырга;

икенче абзацның 3.3.12 пунктындагы «3.3.10» саннарын «3.3.12» саннарына алыштырырга;

3.4.4 пунктындагы «3.3.4 пункты» сүзләрен «3.3.4 – 3.3.6 пунктлары» сүзләре белән алыштырырга;

3.4.5 пунктындагы «3.3.5 – 3.3.7» саннарын «3.3.7 – 3.3.9» саннары белән алыштырырга;

3.4.6 пунктындагы «3.3.8 – 3.3.9» саннарын «3.3.10 – 3.3.11» саннары белән алыштырырга;

3.4.8 пунктындагы «3.3.5 – 3.3.7» саннарын «3.3.7 – 3.3.9» саннарына алыштырырга.

3.4.9 пунктындагы «3.3.12 – 3.3.15» саннарын «3.3.14 – 3.3.17» саннарына алыштырырга;

3.5.5 пунктын түбәндәге редакциядә язып бирергә:

«3.5.5. Тәэмин итү белгечләре ведомство арасындагы электрон үзара системасы аша сорап алынган документларны бирәләр.

Әгәр әзерләнү вакыты дәверендә ведомство арасындагы сорауларга җибәрелгән җаваплар Татарстан Республикасы федераль законнары, Россия Федерациясе Хакимияте законнарына туры килгән хокуки актлары урнашылмаган булса, тиешле пункт белән билгеләнгән процедуралар ведомство арасындагы сорауларның оешмага җибәрелгән документларның һәм мәгълүматның бирү биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кире кагу турында Министрлыкка җибәрегән документлар (мәгълүматлар) яки белдерүләр. »;

3.5.9 пунктындагы «3.3.12 – 3.3.15» саннарын «3.3.14 – 3.3.17» саннарына алыштырырга;

3.9 пункты белән түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

«3.9. МФЦ аркылы дәүләт ярдәме күрсәтү

3.9.1. Гариза бирүче дәүләт ярдәмен алу өчен МФЦга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.9.2. МФЦ аркылы дәүләт ярдәме куелган регламентка яраштырып, тиешле тәртип буенча үткәрелә.

3.9.3. Дәүләт ярдәмен алу өчен МФЦга мөрәҗәгать итүчеләрнең документларының процедурасы 3.3 – 3.8 пунктлары туры китереп тиешле Регламент аша үткәрелә. Дәүләт ярдәмене нәтиҗәләре МФЦга җибәрелә.»;

5.9 пунктының 5 нче бүлегенең «вәкиләте органнары» сүзләрен «прокуратура органнары» сүзләре белән алыштырырга;

Идарәлек регламентының кушымтасында (белешмә өчен) «5249-91-49» саннарын «524-91-49» саннарына алыштырырга.

2. Дәүләт мәгълүмат ресурслар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара тәэсир итү бүлегенә (Т.А.Апаевка) хәзерге приказны Татарстан Республикасының икътисад Министрлыгы сайтына урнаштыру мөмкинчелеге тудырырга.

3. Приказны үтәү буенча күзәтү министр урынбасары А.Д.Шамсиевка йөкләнә.

**Министр** **М.Р. Шагиахметов**